**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«12» октябрь 2002 ел № 27/1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берөмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Җирлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 48/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проектын 1 кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Җирлек Советының сентябрендәге 48/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 кушымта нигезендә;

- «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен 3 кушымта нигезендә.

3. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын 2022 елның 01 ноябрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә дип билгеләргә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленина ур., 33А йорт.

4. Түбәндәге составта халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссия төзергә:

1) Әгъләҗева Ф. Ә. – комиссия рәисе;
2) Вильданова Л.Р. – комиссия әгъзасы;
3) Калимуллина С.Р. – комиссия әгъзасы.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссиягә халык тыңлауларын үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә халык тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм җирлек Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — Ф. Ә. Әгъләҗева

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 12 октябрендәге 27/1 номерлы карарына 1 кушымта

**«Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы карары проекты**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 00 ноябрендәге 00 номерлы Совет карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. <u>5 статьяның 1 өлеше 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:</u>**

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә предметы җирлек территориясен тезекләндерү кагыйдәләрен үтәү булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен күрсәтелгән җирлек кагыйдәләре нигезендә тезекләндерүне оештыру;»;

**1.2. <u>5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге редакциядәге 20 пунктны өстәргә:</u>**

«20) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм чаралар уздыру, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү өчен әлеге объектларның хокук ияләре турында белешмәләр җибәрү.»;

**1.3. <u>41 статьяның 1 өлеше 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану мөмкинлеге биргән Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгы юкка чыгу, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт яки Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия чит ил

гражданының башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

**1.4. <u>47 статьяның 1 өлеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану мөмкинлеге биргән Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгы юкка чыгу, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт яки яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия чит ил гражданының башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

**1.5. <u>50 статьяның 1 өлеше 6 пункты өченче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:</u>**

«- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен күрсәтелгән җирлек кагыйдәләре нигезендә төзекләндерүне оештыру;»;

**1.6. <u>50 статьяның 1 өлеше 5 пунктына түбәндәге редакциядәге җиденче абзацны өстәргә:</u>**

«- җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итә һәм чаралар уздыра, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү өчен әлеге объектларның хокук ияләре турында белешмәләр җибәрә;»;

**1.7. <u>50 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«3. Җирлек Башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә керә:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) җирлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре җирлек Башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә бирелергә мөмкин.»;

**1.8. <u>58 статьяның 3 өлеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булырга хокук биргән Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгы юкка чыгу турында эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма

Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булырга хокук биргән Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгы юкка чыккан көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

**1.9. 58 статьяның 3 өлешенә түбәндәге редакциядәге 9.1 пунктчасын өстәргә:**

«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рехсәт яки гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында язма рәвештә, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рехсәт яки гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

**1.10. 88 статьяның 3 өлеше үз көчен югалткан;**

**1.11. 88 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге өченче абзацны өстәргә:**

«- «Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлеген билгеләүче документлар;»;

Уставның 88 статья 7 елешенең еченче-җиденче абзацларын дүртенче-сигезенче абзацлар дип санарга.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 12 октябрендәге 27/1 номерлы карарына 2 кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советына язма рәвештә тезәтмәләр таблицасы формасында түбәндәге үрнәк нигезендә кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проектының тексты | Тезәтелгән текст | Тезәтүне исәпкә алып, карар проекты тексты | Төзәтмәләр авторы (фамилиясе,исеме, атасының исеме, адресы, телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленина ур., 32 йорт;

почта аша:, ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт

яисә факс буенча 8(8552)79-63-36.

Тәкъдимнәр карар проекты җирлекнең мәгълүмат стендаларынада урнаштырылган кеннән 2022 елның 24 октябренә кадәр эш кеннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт;

почта аша: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт

яисә факс буенча 8(8552) 79-63-36.

Гаризалар, халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш кеннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 12 октябрендәге 27/1 номерлы карарына 3 кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Заводавыл җирлеге Советы карары буенча халык тыңлаулары (алга таба – халык тыңлаулары) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Халык тыңлауларында үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар булып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советына халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр җиде кеннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район халкы тора.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынган җирлек халкы катнаша ала.

4. Катнашучылар халык тыңлаулары башланырга 30 минут кала теркәлә башлый.

5. Халык тыңлауларында җирлек башлыгы рәислек итә.

6. Халык тыңлаулары рәислек итүченең катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итүче кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында халык тыңлаулары секретариаты сайлана.

8. Теп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артмаска тиеш.

11. Халык тыңлауларында катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рехсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлаулары барышына кысылырга, аны езәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Халык тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау халык тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар тарафыннан халык тыңлауларын үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне ачыклау өчен, халык тыңлаулары секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мемкин.

16. Тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары беркетмәсенә кертелә. Беркетмә билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче теркем тарафыннан әзерләнә.

18. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка игълан ителергә тиеш.

19. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итү авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.